**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ КАРАР № ______

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 14 августындагы ПР-149 номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль биремне Формалаштыру һәм муниципаль бирем үтәлешен финанс белән тәэмин итү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 14 августындагы ПР-149 номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждениеләргә карата муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) муниципаль биремне формалаштыру һәм муниципаль бирем үтәлешен финанс белән тәэмин итү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең II бүлегендәге 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 1 июлендәге 376 номерлы карары белән расланган хезмәтләр күрсәтүгә һәм эшләр башкаруга карата учреждениеләрнең норматив чыгымнарын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәләрне үтәп, әлеге нигезләмә нигезендә билгеләнә торган чыгымнарның база нормативы нигезендә муниципаль биремдә билгеләнгән хезмәт күрсәтү күләме күрсәткече берәмлегенә (алга таба - норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә) исәпләп чыгарыла.»

II бүлекнең 23 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Эшләрне башкаруга норматив чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 01 июнендәге 376 номерлы карары белән расланган тәртиптә муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләгәндә билгеләнә (эшләрне башкаруга норматив чыгымнарны билгеләүнең башка тәртибе муниципаль бюджет яисә автоном учреждение уставы белән билгеләнмәгән булса).»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе А.А. Корбангалинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.Р.Сираева